| | |
|---|---|
| СОВЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15.12.2025 г. Агрыз № 4-5

Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендә кабул ителгән 48-3 номерлы «Әгерҗе муниципаль районының муниципаль милке һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен арендалаган, файдаланган өчен бурычларны, өстәмә бурычларны (пеня), шулай ук Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафларны кайтарып булмый торган дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан, 2024 елның 13 июлендә кабул ителгән 177-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маенда кабул ителгән «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча кайтарып булмый торган бурычны тану карарларын кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр турында»гы 393 номерлы карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советының 2020 елның 23 июнендә кабул ителгән 48-3 номерлы «Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы муниципаль милке һәм муниципаль милектәге җир участоклары өчен түләнергә тиешле аренда түләүләре, өстәмә түләүләр (пеня), шулай ук Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы бюджетына керә торган административ штрафларны кайтарып булмый торган дип тану һәм исәптән чыгару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең I бүлегенең 2 һәм 2.1 пунктларын түбәндәге редакциядә язарга:

«2) 2002 елның 26 октябрендә кабул ителгән «Несостоятельность (банкротство) турында»гы 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, бюджет алдындагы бурычларны түләүдән азат ителгән шәхси эшкуарны банкрот дип дип тану»;

2.1.) « Банкротлык турында»гы 2002 елның 26 октябрендә кабул ителгән 127-ФЗ номерлы Федераль закон буенча индивидуаль эшмәкәр булмаган гражданны, әлеге Федераль закон нигезендә бюджет алдындагы түләү бурычыннан азат ителү шартларында, банкрот дип тану.

1.2. II бүлекне түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Россия Федерациясе бюджетларына түләүләр буенча кайтарып булмый торган бурыч дип тану турында карар түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

а) оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме);

б) оешманың салым түләүчесе идентификация номеры, төп дәүләт теркәү номеры, салым түләүчене исәпкә кую сәбәбе коды (физик затның идентификация номеры (бар булса);

в) бурыч туган түләү турында мәгълүмат;

г) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны исәпкә алу буенча Россия Федерациясе бюджетлары коды, аның исеме;

д) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч суммасы;

е) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына тиешле түләүләр буенча пеня һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

ж) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча кайтарып булмый торган бурыч дип тану турында карар кабул ителгән дата».

1.3. III бүлекне түбәндәге редакциядә язарга:

«III. Милекне кулланган өчен аренда түләве, пеня һәм административ штрафлар буенча түләп бетермәгән бурычларны исәптән чыгару өчен кирәкле документлар исемлеге

Бурычларны түләп бетермәгән дип тану һәм исәптән чыгару турындагы карар түбәндәге төп документлар булганда кабул ителә:

а) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычлар суммалары турында бюджет керемнәре администраторының белешмәсе;

б) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерү буенча бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган бурычларны түләттерү буенча күрелгән чаралар турында бюджет керемнәре администраторының белешмәсе,

в) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча түләп бетермәгән бурычларны тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

бюджетка түләүләр түләүче физик затның үлеменә бәйле документ яки аның үлгән дип игълан ителүен раслаучы документ;

бюджетка түләүләр түләүче, индивидуаль эшкуар булган гражданның мөлкәтен сатуны яки конкурс производствосын тәмамлау турындагы суд карары, шулай ук

индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан бюджетка түләүләр түләүче физик затның суд карары нигезендә банкрот дип танылу сәбәпле индивидуаль эшкуарлык эшчәнлеген туктатуы турында мәгълүматларны үз эченә алган документ;

бюджетка түләүләр түләүче гражданның мөлкәтен сатуны яки конкурс производствосын тәмамлау турындагы суд карары;

бюджетка түләүләр түләүче оешманы ликвидацияләү сәбәпле эшчәнлеген туктату турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны үз эченә алган документ;

бюджетка түләүләр түләүче юридик затны теркәүче орган карары буенча әлеге реестрдан чыгару турында юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматларны үз эченә алган документ;

штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия акты яки ярлыкау акты яки бюджет керемнәре администраторының бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалткан суд карары.

"Суд пристав-башкаручының "Башкару производствосы турында" Федераль законның 46 статьясы 1 өлешенең 3 яки 4 пункты нигезендә эш кузгату документын түләүчегә кире кайтару сәбәпле башкару производствсын тәмамлау турындагы карары"

әгәр дә банкротлык эше процедураларын үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмаса, бурычлыны банкрот дип тану турындагы гаризаны кире кайтару яки банкротлык эше буенча производствоны туктату турында суд карары (суд акты).

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар;

гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турында белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ.»

2. Әлеге карарны Татарстан Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru), Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru)

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре экология, табигать ресурслары һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Л. Ф. Нургаянов